ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 май,2019 ел № 31/8

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2019 елның 01 апрелендәге «Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 45-ФЗ санлы Федераль законга нигезләнеп

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/8, 2015 елның 09 ноябрендәге № 3/5, 2017 елның 24 октябрендәге 20/6, 2018 елның 10 августындагы 26/10, 2018 елның 08 ноябрендәге 27/12 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру буенча чараларны тормышка ашыру вәкаләтләре Башкарма комитетка йөкләнә.

Башкарма комитет хосусыйлаштыру турында Федераль законның 6 маддәсе 1 пункты 8.1 пунктчасы нигезендә расланган исемлектәге юридик затларга билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырыла торган муниципаль милекне сатуны оештыруны һәм (яки) мондый милекне сатучы функцияләрен башкаруны тапшырырга хокуклы.»;

2) 29 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 16 пунктча белән тулыландырырга:

«16) әлеге Нигезнамәнең 10 пункты нигезендә муниципаль милек сатучы функцияләрен гамәлгә ашыручы һәм (яки) Башкарма комитет карары нигезендә хосусыйлаштырыла торган муниципаль милекне сатуны оештыру йөкләнгән юридик затка түләү күләме һәм тәртибе.»;

3) 34 пунктның пунктчасын яңа түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) сату барышында мондый милеккә сатуда катнашучылар белән чагыштырганда иң югары бәяне тәкъдим иткән, яки сату барышында иң соңгы тәкъдимгә кадәр тәкъдим керткән физик зат яисә юридик зат исеме»;

4) 4) 72 пунктта «гамәлгә ашырыла» сүзләрен «гамәлгә ашырылырга мөмкин» дип үзгәртергә

2. Әлеге Карар 2019 елның 01 июненнән гамәлгә керә.

3. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев